КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 март г.Казань № 383

«Кега» транспорт тарасына тутырылган сыра, сыра нигезендә ясала торган эчемлекләр һәм аз алкогольле эчемлекләрнең кайбер төрләре әйләнешенең барлык этапларында аларның хәрәкәтен күзәтеп торуны тәэмин итү буенча эксперимент үткәрү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән маркировкалау буенча эксперимент үткәрү турында» 2020 ел, 18 февраль, 122 нче карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сыраны, сыра нигезендә ясала торган эчемлекләрне һәм аз алкогольле эчемлекләрнең кайбер төрләрен идентификацияләү чаралары белән маркировкалау кагыйдәләрен раслау һәм сырага, сыра нигезендә ясала торган эчемлекләргә һәм аз алкогольле эчемлекләрнең кайбер төрләренә карата идентификацияләү чаралары белән мәҗбүри маркировкаланырга тиешле товарларның әйләнешен мониторинглау буенча дәүләт мәгълүмат системасын гамәлгә кертү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 30 ноябрендәге 2173 номерлы карары нигезендә «кега» транспорт тарасына тутырылган, идентификацияләү чаралары белән маркировкаланган сыра, сыра нигезендә ясала торган эчемлекләр һәм аз алкогольле эчемлекләрнең кайбер төрләре хәрәкәтен күзәтеп торуны тәэмин итү механизмнарын эшләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 апреленнән Татарстан Республикасы территориясендә, идентификацияләү чаралары белән мәҗбүри маркировкаланырга тиешле товарларның әйләнешен мониторинглау буенча дәүләт мәгълүмат системасына белешмә кертеп, «кега» транспорт тарасына тутырылган сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуаре, әче бал (алга таба – сыра һәм аз алкогольле эчемлекләр) әйләнешенең барлык этапларында аларның хәрәкәтен күзәтеп торуны тәэмин итү буенча эксперимент үткәрергә.

2. Экспериментның максатлары түбәндәгеләр дип билгеләргә:

сыраны һәм аз алкогольле эчемлекләрне идентификацияләү чаралары белән маркировкалау механизмнарының тулылыгын, эффективлыгын, нәтиҗәлелеген һәм җитәрлек булуын апробацияләү һәм мондый продукциянең мониторинг мәгълүмат системасында хәрәкәтен күзәтеп торуны тәэмин итү;

сыраның һәм аз алкогольле эчемлекләрнең чынлыгын раслау;

Татарстан Республикасы территориясендә сыраны һәм аз алкогольле эчемлекләрне законсыз җитештерүгә һәм әйләнештә йөртүгә каршы тору;

бу карарның 4 пунктында күрсәтелгән экспериментта катнашучылар тарафыннан мониторинг мәгълүмат системасында һәр сыра һәм аз алкогольле эчемлекләр бирәмлеге буенча белешмәне теркәп баруны гамәлгә ашыру;

сыра һәм аз алкогольле эчемлекләр әйләнешен исәпкә алу процедураларын унификацияләү;

әйләнештә йөртүдә катнашучыларның һәммәсе тарафыннан маркировкаланган сыраны һәм аз алкогольле эчемлекләрне мониторинг мәгълүмат системасында исәпкә алуга кучүнең максатка ярашлылыгын билгеләү;

әйләнештә йөртүдә катнашучыларның һәммәсе тарафыннан маркировкаланган сыраны һәм аз алкогольле эчемлекләрне мониторинг мәгълүмат системасында исәпкә алуны алып бару турында Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр әзерләү.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең эксперимент үткәрүне тәэмин итүгә вәкаләтле башкарма органы – Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе дип билгеләргә.

4. Экспериментта катнашучылар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе (алга таба – вәкаләтле орган);

б) Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (вәкаләтле орган белән килешү нигезендә);

в) «Оператор-ЦРПТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (вәкаләтле орган белән килешү нигезендә);

г) экспериментта үз теләге белән катнашкан сыра һәм аз алкогольле эчемлекләр җитештерүчеләр һәм аларны чит илләрдән кертүчеләр, Татарстан Республикасы территориясендә мондый продукцияне сатып алуны, саклауны һәм кайтартуны,

шулай ук ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр.

5. Вәкаләтле орган тарафыннан бу карарда каралган чаралар 2023 елга вәкаләтле органның билгеләнгән штат саны лимиты һәм аны тотуга финанслау күләмнәре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән маркировкалау буенча эксперимент үткәрү турында» 2020 ел, 18 февраль, 122 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Бу карар 2023 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин